КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 27 апрель

г.Казань

№ 343

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 – 2020 елларга Татарстан Республикасында архив эшен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2016 ел, 10 июнь, 395 нче карары белән расланган «2016 – 2020 елларга Татарстан Республикасында архив эшен үстерү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 – 2022 елларга Татарстан Республикасында архив эшен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2016 ел, 10 июнь, 395 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 5 июнь, 342 нче; 2017 ел, 12 сентябрь, 650 нче; 2017 ел, 27 ноябрь, 911 нче; 2018 ел, 14 май, 363 нче; 2018 ел, 24 декабрь, 1211 нче, 2019 ел, 22 июль, 610 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2016 – 2022 елларга Татарстан Республикасында архив эшен үстерү» дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа исемендә «2016 – 2020» саннарын «2016 – 2022» саннарына алмаштырырга;

Программа паспортында «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, финанслау күләмнәре | Программаны Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслауның гомуми күләме 1 683 074,7 мең сум тәшкил итә, шул исәптән еллар |

| | |
|---|---|
| | буенча:<br>2016 ел – 131 029,4 мең сум;<br>2017 ел – 264 939,7 мең сум;<br>2018 ел – 269 808,0 мең сум;<br>2019 ел – 281 443,9 мең сум;<br>2020 ел – 251 487,6 мең сум;<br>2021 ел – 241 384,7 мең сум;<br>2022 ел – 242 981,4 мең сум.<br>Искәрмә. Программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм тиешле финас елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетын формалаштырганда ел саен тәгаенләнергә тиеш»; |

III бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. Программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Программаны тормышка ашыруны финанслар белән тәэмин итү Татарстан Республикасының законнар белән билгеләнгән тәртиптә бирелә торган бюджет акчасын файдалануны күздә тота.

Программаны финанслауның гомуми күләме 1 683 074,7 мең сум тәшкил итә,шул исәптән еллар буенча:

2016 ел – 131 029,4 мең сум;
2017 ел – 264 939,7 мең сум;
2018 ел – 269 808,0 мең сум;
2019 ел – 281 443,9 мең сум;
2020 ел – 251 487,6 мең сум;
2021 ел – 241 384,7 мең сум;
2022 ел – 242 981,4 мең сум.

Программаны тормышка ашыруны ресурслар белән тәэмин итү фараз характерында була һәм, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен тәгаенләнергә тиеш.»;

Программага теркәлгән кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин